| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ БИЗЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28 март 2024 ел N 3

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлегендә
бюджет процессы турында
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 628-ФЗ номерлы Федераль законына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Советының 2022 елның 22 мартындагы 2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
12 статьяның 2 өлешен 16 пункт белән тулыландырырга һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«16) иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмати системасында «Электрон бюджет» капиталь төзелеш объектлары күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат формалаштыра, капиталь кертемнәрне финанс белән тәэмин итү (финанслашу) чыганагы булып федераль бюджет акчалары тора (капиталь төзелеш объектларыннан һәм дәүләт оборона заказына кертелгән күчемсез милек объектларыннан тыш).».
2. Әлеге карарны Бәзәкә авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына урнаштырып игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында " Бәзәкә авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

Бәзәкә авыл җирлеге Советы рәисе И.И. Кәшәфетдинов